08.09.2022

№ 1

# РЕШЕНИЕ (КАРАР)

## 2022 нче елның 08 нче сентябрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Килдебәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Мәртен торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел, № 21 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, 2022 нче елның 08 нче сентябрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең Мәртен торак пункты территориясендә гражданнар җыены кабул иткән карар нигезендә:

Килдебәк авыл җирлегенең Мәртен авылы халык җыенында катнашу өчен сайлау хокукына ия булган 29 кеше кертелгән, халык җыенында катнашучылар 17 бу исемлеккә кертелгән кешеләрнең 58,6% ын тәшкил итә.

Көн тәртибендәге мәсьәлә буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә билгеләнде:

«Әйе» позициясе өчен 17 кеше тавыш бирде, бу гражданнар җыенында катнашучыларның 100% ын тәшкил итә, «юк» позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде,бу 0% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Советы карар итә:

1.2022 нчы елның 08 нче сентябрендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Килдебәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Мәртен торак пункты территориясендә гражданнар җыенын үткән дип, аның нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2."2023 нче елда Саба муниципаль районының Килдебәк авыл җирлеге Мәртен торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны Мәртен авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау өчен тотарга дигән сорау белән килешәсезме? дигән карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/kildebiak бастырып чыгарырга.

Килдебәк авыл
җирлеге башлыгы

Н.Н.Заһидуллин